**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

__01.06.2023____ г. Казань **№**____71од_____

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына коррупция юнәлешле фактлар буенча кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2018 елның 31 июлендәге 80 од номерлы (2022 елның 26 сентябрендәге 157од номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына коррупция юнәлешендәге фактлар буенча кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге тарафыннан мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып ике эш көненнән артмаган срокта «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә хезмәткәргә карата хезмәт тикшерүе үткәрү инициативасы куела (хезмәткәрдән язма аңлатмалар таләп ителә).»;

4 пунктның икенче абзацына «хезмәт тикшерүе» сүзләреннән соң «, шулай ук хезмәткәрнең язма аңлатмаларын анализлау» сүзләрен өстәргә.

Министр Р.И. Заһидуллин